ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

06.02.2020 п.г.т.Алексеевское № 48

**«Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы территориясендә яшәүче балаларга өстәмә белем бирүне оештыру турындагы нигезләмәне раслау хакында» Алексеевск муниципаль районы башкарма комитетының 2015 елның 16 апрелендәге 195 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Эшчәнлекнең аерым төрләрен лицензияләү буенча дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең реестр моделен кертү өлешендә Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 27 декабрендәге 478-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләренә туры китерү максатларында

**карар кылам:**

1. «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы территориясендә яшәүче балаларга өстәмә белем бирүне оештыру турындагы нигезләмәне раслау хакында» Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының 2015 елның 16 апрелендәге 195 номерлы карарына үзгәреш кертергә һәм 4.4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешма үз уставы белән, белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыруга лицензияне бирү датасы һәм теркәү номеры турында белешмәләр, дәүләт аккредитациясе турында таныклык, белем бирү эшчәнлеген оештыруны һәм гамәлгә ашыруны регламентлаштыручы мәгариф программалары һәм башка документлар белән танышырга тиеш. Конкурс нигезендә кабул итү үткәрелгәндә шулай ук үткәрелә торган конкурс турында һәм аны уздыру йомгаклары турында мәгълүмат бирелә».

2. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы мәгариф учреждениеләре җитәкчеләренә әлеге карарга Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы муниципаль мәгариф учреждениеләрендә балаларга өстәмә белем бирүне оештырганда таянырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны социаль мәсьәләләр буенча башкарма комитет җитәкчесе урынбасары Н.П. Чуринга йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **Н.К. Кадыйров**